КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 4 март г.Казань № 128

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2023 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында» 2019 ел, 29 март 242 нче карары белән расланган 2019 – 2023 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2023 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын раслау турында» 2009 ел, 29 март, 242 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 31 гыйнвар, 59 нчы, 2020 ел, 15 июль, 596 нчы, 2021 ел, 15 гыйнвар, 10 нчы, 2021 ел, 19 июль, 588 нче, 2022 ел, 19 август, 867 нче, 2022 ел, 17 декабрь, 1361 нче, 2024 ел, 26 гыйнвар, 33 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2019 – 2023 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлында:

икенче абзацта «733 321 423,26» саннарын «730 515 089,97» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «353 964 721,28» саннарын «353 684 605,28» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «15 131 058,46» саннарын «14 852 898,65» саннарына алмаштырырга;

бишенче абзацта «1 102 417 203,0» саннарын «1 099 052 593,9» саннарына алмаштырырга;

Программаның I бүлегендә:

дүртенче абзацта «1 758» саннарын «1 784» саннарына алмаштырырга;

җиденче абзацта «Торак-коммуналь хуҗалык реформасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

Программаның III бүлегенең бишенче абзацында «1 102 417 203,0» саннарын «1 099 052 593,9» саннарына алмаштырырга;

Программаның IV бүлегенең дүртенче абзацында «Торак-коммуналь хуҗалык реформасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

Программаның V бүлегендә:

беренче абзацта «1 102 417 203,0» саннарын «1 099 052 593,9» саннарына алмаштырырга;

икенче абзацта «733 321 423,26» саннарын «730 515 089,97» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «353 964 721,28» саннарын «353 684 605,28» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «15 131 058,46» саннарын «14 852 898,65» саннарына алмаштырырга;

әлеге Программага 1 нче кушымтаның «2019 - 2023 елларга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасын (алга таба – Программа) үтәү нәтиҗәсендә күчеренгән халык саны» юлында «1 758» саннарын «1 784» саннарына алмаштырырга;

әлеге Программага 2 – 5 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин